**Яңа Спас авыл җирлеге Советы**
**Зәй муниципаль районы**
**Татарстан Республикасы**

# КАРАР

**№1 52** **07 октябрь 2019ел.**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлеге Советының 2014 елның 28 февраль 90 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмә хакында» гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, 2007 нче елның 2 нче мартындагы 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законга, Татарстан Республикасының 2013 нче елның 25 нче июнендәге 50-ЗРТ номерлы «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» Законына, Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге Уставы нигезендә , Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлеге Советының 2014 елның 28 февраль 90 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмә хакында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. 20 статьяның 3 өлешендәге 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«6) индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында, шул исәптән электрон документ формасында теркәлүне раслый торган документ;»;
1.2. 29 статьяның 6 өлешендә «ә стажның дәвамлылыгы һәм айлык түләүләр кодекс нигезендә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия күләмен билгеләгәндә муниципаль хезмәткәргә билгеләнгән шундый ук дәрҗәдә исәпкә алына» сүзләрен « ә сыйныф чины өчен вазыйфаи окладка ай саен өстәмә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларын билгели торган норматив хокукый актында билгеләнгән дәрәҗәдә исәпкә алына» сүзләренә алмаштырырга.
2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырып чыгарырга һәм Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту үз артымнан калдырам.

Совет рәисе А.С.Быля